12. Nasyiri, K. (1992). *Kitab-ət-tərbiya* [A Book about Education]. 144 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

13. Məkhmytov, M. I., Khəmzin, K. Z., Səifullin, G. Sh. (1993). *Garəpchə-tatarcha-ruscha alynmalar syzlege (tatar ədəbiyatynda kullanylgan garəp həm farsy syzləre) 2 t.* [Dictionary of Arabic-Tatar-Russian Borrowings. (Arabic and Persian Words Used in Tatar Literature)]. 786 p. Kazan, Iman. (In Tatar)

14. Bigiev, Z. (1991). *Zur gønahlar* [Great Sins]. 228 p. Kazan, Tat. kit. nəshr. (In Tatar)

15. Əkhmət'yanov, R. R. (2001). *Tatar teleneң kyskacha tarikhi-ehtimologik syzlege* [A Brief Historical-Etymological Dictionary of the Tatar Language]. 272 p. Kazan: Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

16. Toirova, G. I. (2009). *Nutқii muloқotning pragmatik taҳlilida sistema tushunchasi* [The Concept of System in the Pragmatic Analysis of Verbal Communication]. Filologiya masalalari. No. 1, pp. 26–31. Toshkent, ЎZDZHTI. (In Uzbek)

# ТАТАР ҺӘМ ҮЗБӘК ЛИНГВОМӘДӘНИЯТЕНДӘ СӘЛАМЛӘҮ ГЫЙБАРӘЛӘРЕНЕҢ КОММУНИКАТИВ-ПРАГМАТИК КУЛЛАНЫЛЫШЫ

**Фирүзә Рәмзил кызы Сибгаева,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
FiruzaRS@mail.ru

**Гули Ибраһим кызы Тоирова,**
Бохара дәүләт университеты,
Үзбәкстан, 200114, Бохара ш., М.Икбола ур., 11 нче йорт,
tugulijon@mail.ru

Әлеге фәнни мәкалә мәдәниятара коммуникация, коммуникатив лингвистика теорияләре юнәлешендә башкарылды. Тикшеренү объекты – татар һәм үзбәк телләрендә сәламләү гыйбарәләре, аларның прагмалингвистик үзенчәлекләре тикшеренү предметы булып тора.

Мәкаләдә татар һәм үзбәк телләрендәге сәламләү фрмаларының чагыштырма анализ нәтиҗәләре китерелә. Фәнни хезмәттә тел, сөйләм, коммуникатив аерымлыклар һәм охшашлыклар, милли аң үзенчәлекләре ачыкланды. Тәкъдим ителә торган мәкалә гамәли юнәлештә.

Тикшеренү барышында анализ, күзәтү, чагыштыру, компонентлы анализ методлары һәм алымнары кулланылды.

**Төп төшенчәләр:** татар теле, үзбәк теле, сәламләү гыйбарәләре, мәдәниятләр диалогы, аралашу мәдәнияте, лингвомәдәният

## Кереш

Сөйләмебезгә игътибар итсәк, аралашу ситуацияләрендә еш кабатлана торган гыйбарәләр, этикет формалары белән очрашабыз: *«Исәнмесез!»; «Хәлләрең(-гез) ничек?»; «Исән-сау йөр»; «Әйт(егез) әле…»; «Эшләрең(-гез) уң булсын!»* һ.б. Көнкүрештә аралашу, бер үк фразаларның күп кабатлануы стереотиплар күплеген китереп чыгара. Нәкъ менә шулар сөйләм әдәбен тәшкил итә дә. Еш кабатлана торган ситуацияләрдә, аралашканда, өр-яңа фразалар төзеп тормыйбыз, әзер гыйбарәләрне файдаланабыз. Исәнләшү, саубуллашу, котлау, теләкләр, мөрәҗәгать, рәхмәт белдерү һ.б. төрле темаларга караган аралашу гыйбарәләре була. Аларның көндәлек кулланылышта иң еш очрый торганнары сөйләүлекләргә кертелә. Сөйләм гыйбарәләре төрле халыкта төрлечә. Һәр халыкның үзенчәлекле сөйләм әдәбе була. Аны өйрәнергә, үзенчәлекләрен ачарга кирәк, чөнки сөйләм әдәбендә телдә чагылыш тапкан катлаулы социаль мәгълүмат ята.

Этикет гыйбарәләре аралашу темасына туры килә торган лексик берәмлекләр һәм грамматик конструкцияләр сайлау, интонацион бизәлеш, вербаль булмаган чаралар белән ярашып кулланыла. Этикет гыйбарәләренең мәгънәсе һәм аралашу тоны күп вакытта мөрәҗәгать итүдә кулланылган сүзләргә генә түгел, ә аның интонацион бизәлешенә һәм башка тел чаралары, аралашу шартлары, әңгәмәдәшләрнең үзара мөнәсәбәтләре белән дә бәйле [1, б. 320].

Татар халкында ихлас итагатьлелекне, кече күңеллелекне, әдәплелекне чагылдырган сүзләргә сәлам бирү, саубуллашу, рәхмәт әйтү, үтенү, гозерләү, киңәш-табыш итү, котлау, гафу үтенү һ.б. сөйләм гыйбарәләре дә керә. Сөйләм әдәбе гыйбарәләре лингвомәдәнияттә, телне чит тел буларак өйрәткәндә дә, туган телне өйрәнгәндә дә, аеруча әһәмиятле урын алып тора.

Аралашу исәнләшүдән башлана, саубуллашу белән тәгәлләнә. Димәк, *исәнләшү һәм саубуллашу гыйбарәләре* – сөйләм әдәбенең әһәмиятле өлешләреннән берсе. Әңгәмәдәш белән эшлекле, ихлас мөнәсәбәт урнаштыру аның белән итагатьле исәнләшүдән башлана. Исәнләшү гыйбарәсен сайлау күп очракта әңгәмәнең нинди булачагын хәл итә. Шуның белән бергә ул әңгәмәдәшнең игътибарын үзенә җәлеп итү өчен дә кулланыла. Сөйләүче, исәнләшкәндә, аңа үзенең мөнәсәбәтен (дуслык, рәсми мөнәсәбәт, бер-береңне ихтирам итү, олылау һәм башка мөнәсәбәтләрне) белдерә.

### Тикшеренү материаллары һәм методлары

Сөйләм әдәбе, аның аерым коммуникатив-прагматик кулланылышы, этик гыйбарәләр, сөйләм актлары һ.б. мәсьәләләр тел белемендә өйрәнергә кирәкле актуаль мәсьәләләрнең берсе. Татар тел гыйлемендә сөйләм әдәбе мәсьәләләрен махсус рәвештә өйрәнгән хезмәтләр бик аз. Бу юнәлештә дөнья күргән сөйләм мәдәнияте, сөйләм гыйбарәләрен гамәли яктан дөрес куллану, чит тел буларак, татар телен өйрәтүдә этикет формаларын куллануга мөнәсәбәтле фәнни хезмәтләрне билгеләп үтәргә кирәк. Шунысы әһәмиятле: сөйләм әдәбе мәсьәләләрен чагыштырма планда өйрәнү, тикшерүне тагын да тирәнәйтә, теге яки бу халыкка хас менталь, лингвомәдәни үзенчәлекләрне, уникалий һәм универсалийларны билгеләргә ярдәм итә. Төрки телләрнең сөйләм әдәбе гыйбарәләрен чагыштырып өйрәнгәндә, аралашу чараларына әлеге халыкның фикерләү, чынбарлыкны кабул итүен чагылдыра торган билгеле бер милли колорит өстәлүен ачыкларга мөмкин. Этикет гыйбарәләренең кулланылыш үзенчәлекләре, бигрәк тә бу мәсьәләне ике тел мисалында чагыштырып өйрәнү – кызганыч, татар тел гыйлемендә өйрәнелмәгән мәсьәлә.

Безнең тарафтан тәкъдим ителә торган фәнни мәкаләнең актуальлеген татар һәм үзбәк халкында сәламләү, аңа бәйле гыйбарәләрнең кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү мәсьәләсе билгели. Моның сәбәпләрен милләтара бәйләнешләрнең киңәюе, төрле халыкларның милли көнкүреше белән кызыксыну арту һәм моны аңларга омтылу, бигрәк тә коммуникатив, прагматик һәм лингвомәдәният фәненең актив үсеш алуы белән бәйләп аңлатырга мөмкин.

Тәкъдим ителә торган мәкалә гамәли юнәлештә. Тикшеренү барышында анализ, күзәтү, чагыштыру, компонентлы анализ методлары һәм алымнары кулланылды.

### Фикер алышу

Этика фәнендә ике юнәлеш билгеләнә. Беренчесе – кешенең үз-үзен тотуы, киенүе һ.б., икенчесе – сөйләм әдәбе. Аралашу процессында, кешеләр белән бәйләнешкә кергәндә, билгеле бер мөнәсәбәтләр урнаша. Бу мөнәсәбәтләр телдә дә чагылыш таба һәм алар тотрыклы тәгъбирләр системасына әйләнеп киткән (танышу, гафу үтенү һ.б.). Шушы тотрыклы мөнәсәбәтләрнең җыелмасы сөйләм әдәбе дип атала [2, б. 189].

Этикет – әхлак культурасының бер өлеше. Ул зыялылык, мәдәниятле һәм әдәпле булу белән ассоциацияләнә. Кешенең нинди этикет билгеләрен сайлавына карап, без аңа әхлакый бәя бирәбез. Болар – этикетның төп эчтәлеген хасил итә торган әһәмиятле яклар [1, б. 321].

Хәзерге тел белемендә сөйләм әдәбенә түбәндәге билгеләмә бирелә: «Сөйләм әдәбе ул – аралашуны әңгәмәдәшләрнең иҗтимагый рольләренә, социаль статусларына туры китереп, аларның үзара мөнәсәбәтләренә бәйле сайланган тональлектә, билгеле бер стильдә, рәсми яки рәсми булмаган шартларда дәвам иттерү максаты белән сөйләм контакты урнаштыру өчен җәмгыять тарафыннан билгеләнгән тотрыклы формулалар системасы» [3, б. 88].

Сөйләм әдәбе турында сүз алып барганда, аның сөйләм акты булуын истә тотарга кирәк. Сөйләм акты – сөйләм ярдәмендә гамәл башкарылу. Аралашу ситуацияләренең һәркайсында сөйләм әдәбенә караган гыйбарәләрнең системалы оешкан коммуникатив-мәгънәви төркемнәре бар. Н.И. Формановская хезмәтләренә нигезләнеп, Ф.С. Сафиуллина, К.С. Фәтхуллова һ.б. галимнәр аралашуда түбәндәге ситуатив-тематик төркемнәрне аерып күрсәтәләр: «Мөрәҗәгать һәм игътибарны җәлеп итү», «Сәламләү», «Танышу», «Саубуллашу», «Гафу үтенү», «Рәхмәт белдерү», «Котлау», «Теләкләр», «Кайгы уртаклашу», «Кеше хәленә керү», «Чакыру», «Тәкъдимнәр», «Үтенеч белдерү», «Киңәш бирү», «Ризалык белдерү», «Сорау, үтенеч һәм башка шундыйларны кире кагу», «Хуплау», «Комплимент» һ.б. [4, б. 70–78]. Фәнни-теоретик тикшеренүләрдән күренгәнчә, андый төркемнәрнең, аларны белдерү формаларының шактый күп булуын күрергә була. Барлык телләр сөйләм әдәбе хәл-әхвәл сорашу, гафу үтенү, чакыру гыйбарәләренә бик бай.

Әлбәттә, сөйләм әдәбе мәсьәләләре, аерым сөйләм гыйбарәләре телчеләрнең игътибарын һәрдаим җәлеп итә, чөнки сөйләм әдәбе – лингвомәдәниятнең, сөйләм әдәбенең бер өлеше. Аны өйрәнү билгеле бер милләт вәкиле аралашуының үзенчәлекләрен ачарга, менталитетын аңларга ярдәм итә. Шуның белән бергә сөйләм әдәбе тел нормаларын урнаштыру, аларны саклау юнәлешендәге мәсьәләләрне яктыртканда да, телгә алынырга тиеш.

Рус теле гыйлемендә сөйләм әдәбен лингвистик һәм социаль күренеш буларак өйрәнүгә А.А. Акишина, С.В. Андреева, С.И. Виноградов, Г.П. Грайс, Е.А. Земская, М.А. Кобозева, К. Смолка, С.Г. Тер-Минасова, Н.И. Формановская һ.б. галимнәрнең хезмәтләре багышланган.

Алда аталган авторларның хезмәтләрендә сөйләм әдәбе социолингвистик һәм методологик яктан карала: типик аралашу ситуацияләре белән бәйле булган төп сөйләм гыйбарәләре билгеләнә һәм аларның башка телләрдәге эквивалентлары ачыклана. Сөйләм әдәбе мәсьәләләрен яктыртуда күп төрле проблемаларны колачлап алуы белән Н.И. Формановская хезмәтләре аеруча зур әһәмияткә ия.

Н.И. Формановская хезмәтләрендә ситуатив-тематик төркемнәрне билгеләүгә зур игътибар бирелә. «Речевой этикет и культура общения» хезмәтендә әлеге төркемнәрнең саны 15 итеп билгеләнә: 1) сәламләү; 2) мөрәҗәгать итү, игътибар җәлеп итү; 3) танышу; 4) чакыру; 5) үтенеч, киңәш, тәкъдим; 6) үтенечкә һәм чакыруга җавап итеп ризалык һәм кире кагу; 7) фикер белән ризалык һәм килешмәү [4, б. 92].

Сөйләм әдәбенең кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә гаять әһәмиятле булуын ассызыклап, Н.И. Формановская «сөйләм әдәбе аралашу вакытында без алмаша торган мәгълүматның махсус өлешен генә чагылдырып калмый, кешеләрнең бер-берсе белән мөнәсәбәтләренә “ишек ача”» дип билгели. Шуңа бәйле сөйләм гыйбарәләрен төп 3 төркемгә бүлә: 1) аралашуны башлап җибәрә торган сөйләм формалары (сәламләү, танышу, мөрәҗәгать итү); 2) аралашу дәвамында кулланыла торган гыйбарәләр; 3) аралашуны тәмамлый торган сөйләм берәмлекләре (хушлашу-саубуллашу).

Татар теле белемендә дә бу юнәлештә монографик хезмәтләр шактый. А.А. Абдуллинның «Хәзерге татар әдәби телендә сөйләм әдәбе гыйбарәләре» исемле филология фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсен алу өчен язылган диссертациясен (2006) билгеләп үтәргә кирәк. Бу хезмәттә автор, бай тел материалына таянып, гафу үтенү, кешене мактау, исәнләшү, яхшы теләк гыйбарәләрен тикшерә, аларның лексик-семантик, морфологик, стилистик, синтаксик үзенчәлекләрен ачыклый, күп кенә гыйбарәләрнең күп функцияле булуын исбатлый [5, б. 200].

А.А. Абдуллин татар телендәге этик гыйбарәләрне ситуатив-тематик төркемнәргә бүлә: 1) Сәламләү (Исәнме (сез)! Ни хәлләрегез бар?); 2) Ихтирамлы мөрәҗәгать (ханым, туташ, абыстай, хәзрәт); 3) Саубуллашу (Сау бул(ыгыз)! Исән бул(ыгыз)! Хәерле юл!); 4) Рәхмәт белдерү (Рәхим итегез! Кулыңнан куан!); 5) Үтенеч (Зинһар өчен! Алла ризалыгы өчен!); 6) Үтенечне үтәүгә әзерлек (Бик теләп… Бик рәхәтләнеп…); 7) Гафу үтенү (Гафу ит(егез). Риза-бәхил); 8) Котлау (Котлы булсын! Мөбарәк булсын!); 9) Теләк (Аш(лар)ыгыз тәмле булсын! Авызыңа бал да май!); 10) Игътибар җәлеп итү (Гафу итегез, вакыт күпме? Рәхим итеп, кертегез әле…); 11) Мактау (Бар икән игелекле кешеләр!); 12) Танышу (Таныш булыгыз… Таныш булыйк..); 13) Чакыру (Рәхим итсәгез иде); 14) Сыйлау (Ни барыннан җитешеп утырыгыз… Хәзинәдә бары белән…); 15) Киңәш бирү (Олыны олы, кечене кече итәргә кирәк); 16) Әйтелгәннәр белән килешү (Нәкъ үзе!); 17) Тынычландыру (Борчылма, Кайгырма…); 18) Кешенең кайгысын уртаклашу (Үлгән артыннан үлеп булмый…); 19) Шатлыклы хәбәр (Сөенче, сөенче, атыгыз колынлаган) [5, б. 3].

Татар сөйләм әдәбен өйрәнүдә Г.М. Шәйхиева эшчәнлеген аерым билгеләп үтәргә кирәк. Ул үзенең фәнни хезмәтләрендә сөйләм әдәбенең гомуми аспектларын өйрәнү белән беррәттән, эндәшү, гафу үтенү формаларын, этикет сүзләрнең морфологик һәм стилистик үзенчәлекләрен яктырта [1, б. 322].

Татар тел гыйлемендә бу өлкәгә караган кандидатлык диссертацияләре язылу да бу юнәлештә эзләнүләрнең җитди булуын күрсәтә. Л. А. Хисамованың «Сопоставительное исследование вербальных и невербальных средств коммуникации татарского и английского языков» (2009) диссертациясе аеруча игътибарга лаек. Хезмәттә татар тел гыйлемендә беренче тапкыр татар һәм инглиз теле системаларындагы вербаль һәм вербаль булмаган аралашу чараларына комплекслы типологик чагыштырма һәм коммуникатив-прагматик анализ ясала. Хезмәттә тикшерү объекты итеп татар һәм инглиз сөйләмендә сәламләү, танышу, саубуллашу һәм теләк ситуатив-тематик төркемнәре алына.

Сөйләм әдәбе мәсьәләләре төрки телләрдә дә актив рәвештә тикшерелә. Төрки тел белемендә Ф.Ф. Солтанов (1982), Д. Согдыкбекова (1982), К.Э. Гаджиева (1988), Э.Ф. Ишбирдин (1998), З.И. Сәләхова (2004),

А.В. Кузнецов (2004) һ.б. галимнәр этикет гыйбарәләренә игътибар итәләр.

Үзбәк тел гыйлемендә А.А. Муминова үзбәк теленең сөйләм әдәбе проблемаларын тикшерә һәм зат алмашлыгын берлек һәм күплек санда кулланып, теләкләр, ата-аналар һәм балалар, ир белән хатын арасындагы һ.б. аралашканда, сөйләм ситуацияләрендә аларны куллану үзенчәлекләрен ачыклый [6, б. 34]. Шулай ук, бер үк этикет гыйбарәләренең төрле диалект вәкилләрендә кулланылыш аерымлыкларын да күрсәтә.

М. Миртожиевның хезмәтләрендә сөйләм әдәбе, сөйләм культурасы, аралашу серләре, үзбәк халкының аралашу барышында үзүзләрен тоту тәртибе, милли, рухи үзенчәлекләр өйрәнелә [7, б. 69].

Х.А. Хожиева рус телле укучыларны сөйләм әдәбе формулаларына өйрәтүнең үзенчәлекләрен өйрәнә. Сөйләм әдәбе берәмлекләрен мәдәният, яшәү рәвеше кебек күренешләрне билгеләүче тел берәмлекләре буларак карый. Үзбәк теленең сөйләм әдәбендә иң күп кулланыла торган гыйбарәләрне һәм аларның рус телендәге тәңгәллеген тикшерә. Тикшеренү нәтиҗәләре, милли-мәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алып, үзбәк теленең сөйләм әдәбе формулаларының үзенчәлекләрен һәм аларның рус телендәге тәңгәллеген күрергә мөмкинлек бирә һәм рус телле укучыларда үзбәк халкы дөньясының милли тел картинасы турында тулы күзаллау формалаштыруга ярдәм итә, ди галимә [8, б. 74].

Шул рәвешле, сөйләм әдәбен һәм аның билгеле бер ситуатив-тематик төркемнәрен өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтләр булуы куанычлы, алар һәрдаим басылып тора. Шулай да бу әле прагмалингвистик юнәлештәге хезмәтләрнең, тикшеренүләрнең башлангычы гына. Сөйләм әдәбе гыйбарәләрен тәрбияви яктан, тел байлыгы, милли-мәдәни үзенчәлекләренә бәйләнештә өйрәнү кызыклы нәтиҗәләргә килергә ярдәм итә.

Кешеләр сәламне күптөрле формаларда бирә алалар. Мәсәлән, тибетлылар исәнләшкәндә, баш киемнәрен уң кул белән сала. Сул кулны колак артына күтәреп куя, өстәвенә телен дә чыгара. Европалылар, гадәттә, эшләпәсен күтәреп, җиңелчә баш ию белән чикләнә. Японнарда сәлам бирү башны уртача түбәнлектә һәм җиңелчә түбән иеп башкарыла. Иртә белән профессорын күргәч, япон студенты аңа уртача гына баш иеп сәлам бирә. Көндез очрашканда, җиңелчә генә баш ия. Профессор студентка сизелер-сизелмәс кенә баш кагып җавап бирә.

Татар *«Хуш килдегез! Керегез! Түргә үтегез!»* дисә, үзбәк «*Әссәламегаләйкүм! Хуш килдегез!»* дип әйтә. Үзенчәлек – татар телендә ишек төбендә торырга ярамый, өйнең түренә – мактаулы җиргә үтәргә тәкъдим ясала. *Түрә* дигән сүзнең этимологиясе дә *түр* сүзе белән бәйле булырга тиеш. Чөнки ул кадерле кунак һәм аның урыны һәрвакыт түрдә була.

Һәрберебез исәнлек-саулык сорашуда гамәлгә кергән «*Саумы?», «Әссәламегаләйкүм!», «Сәлам», «Ни хәлләр*?*»* кебек сүзләрне көн дә урынлы һәм белеп куллана. Әңгәмәдәш таныш булу-булмау бик әһәмиятле. Шуңа карап дусларча, җылы, интим мөнәсәбәтләр яисә салкын, әдәпле, рәсми мөнәсәбәтләр урнаша. Кешенең яше, иҗтимагый статусы, белем дәрәҗәсе һ.б. факторлар да гаять әһәмиятле. Әңгәмәдәш теге яки бу кешегә алдагы факторларга бәйле рәвештә теге яки бу форманы сайлый.

Динебездә исәнләшү тәртибе беренче булып сәламләгән кеше сөннәт гамәлен үтәсә, җавап кайтарганы өстендәге фарызны үтәгән була. Бу мәсьәләдә Коръәни-Кәримдә болай диелә: «*И мөэминнәр! Әгәр сезгә берәүдән бүләк бирелсә, бүләк бирүчегә үзегез алган бүләк хәтле яки артыграк итеп бирегез! Шиксез, Аллаһ һәрнәрсәне хисап кылучы. (Бүләкнең һәр мөэмин өчен мөмкин һәм лязем булганы сәлам бирү һәм кайтарудыр)»* [9]. Сәламгә җавап кайтару исә фарыз кифая гамәл санала. Бу фарызның шундый төре: аны җәмәгатьнең бер өлеше үтәсә, башкалар бу гамәлне эшләмәү җаваплылыгыннан котыла. Әгәр бу фарызны беркем дә үтәмәсә, аның җаваплылыгы (гөнаһы) бөтен җәмәгатькә төшә [10]. Исәнләшүнең сөннәт гамәл булуы татар мәкальләрендә дә искәртелә. Мәсәлән, *Сәүдәдә дуслык юк, сәламдә бурычлык юк* [11].

XIX гасырда татар халкының педагогик культурасын үстерүгә күп көч куйган галим, мәгърифәтче, педагог һәм язучы Каюм Насыйри үзенең «Китаб-әт-тәрбия» хезмәтендә әдәп-әхлак турында йөз унөч үгет-нәсихәт туплый. 106-107 нче тәрбияләрдә исәнләшү турында ул болай дип яза: «*Сәлам бирсәң, ишеттереп бир, сәлам алсаң, ишеттереп ал. Ягъни сәламне ишеттереп бирмәсәң, гүяки син сәлам бирмәдең, әгәр ишеттереп алмасаң, шулай ук сәламне алмаган кебек буладыр. Әгәр бер кеше дә булмаган бер өйгә барып керсәң дә, сәлам бирү тиеш»* [12, б. 30].

Төрки халыкларда, шул исәптән үзбәк халкында да, сәлам бирүнең төп кагыйдәләре, нигездә, охшаш. Кешеләр төрле формада, төрле ысуллар ярдәмендә исәнләшә, бер-берсенә хәерле иртә, хәерле көн, хезмәттә уңыш, саулык-сәламәтлек, иминлек тели.

Татар мәдәниятендә сәлам бирүнең төп кагыйдәләре шундый: ир кеше – хатын-кыз белән, яшьрәк кеше – өлкәннәр белән, хезмәткәр җитәкче белән беренче булып исәнләшергә тиеш. Ирләргә бер-берсе белән һәрвакыт кул биреп күрешергә киңәш ителә, ә хатын-кызга кул бирү ике якның да теләгенә бәйле. Исәнләшкәндә, уң кулыңны бирү – борынгы йола, аның мәгънәсе – кулыңда корал юк икәнне аңлату. Хәзерге вакытта кул биреп күрешү – яхшылык теләү, ихтирам итү билгесе. Ир кешене хатын-кыз белән таныштырганда, беренче булып хатын-кыз кул бирә. Бу кагыйдәне өлкән кешеләргә карата куллану да урынлы. Дөньяның күпчелек илендә, шул исәптән бездә дә, кияүдәге хатын-кызларның гына кулын үбү гадәткә кергән. Беренче булып яшьләр исәнләшә, ә ир-атлар хатын-кызларны сәламли. Әгәр ир-ат күпкә өлкәнрәк булса, хатын-кыз беренче булып сәламли. Бүлмәгә кергән кеше, ир-ат яки хатын-кыз булуга карамастан, кешеләр белән беренче исәнләшә, китүче – беренче булып калучылар белән саубуллаша. Бүлмәдә берничә кеше булганда, башта өй хуҗа белән, аннары башкалар белән исәнләшәләр.

Үзбәк мәдәниятендә дә кешенең яшенә бәйле исәнләшү, сабуллашу гыйбарәләре мөһим роль уйный. Үзбәк телендә дә сәламләү формулалары бар, аларны куллану түбәндәгеләргә бәйле: 1) адресат һәм сөйләшүче яшенә бәйле; 2) партнёрлар арасында дистанцияләр: чит, таныш, дус, туган; 3) партнёрларның социаль иерархиясе; 4) аралашу вәзгыяте (көнкүреш яки рәсми); 5) адресатның һәм сөйләшүченең җенесенә.

Исәнләшкәндә, кешеләр еш кына вербаль булмаган чаралар да куллана. Татарлар исәнләшү, хәл сорашу, сәламләү вакытында җиңелчә баш ия, кул селки. Сәламләү вакытында күзне йомарга ярамый. Исәнләшкәндә, кешене җылы караш белән сәламләү урынлы, усал яки артык җитди караш ташлаган очракта, әңгәмәдәшче уңайсыз хәлдә яки югалып калырга мөмкин һ.б.

Үзбәк халкында исәнләшүгә бәйле шулай ук берничә вербаль булмаган чара бар: гәүдәне гәүдәгә тидерү, кул биреп исәнләшү яисә кулдан үбү. Гадәттә, башта яшьрәк кешеләр олыларны, бигрәк тә, җәмгыятьтә югары урын алып торучы өлкәннәрне сәламлиләр. Яшьләр олы кешеләргә кул биреп исәнләшәләр, бу рәвешле исәнләшү дуслык, хөрмәт билгесе булып санала.

Очрашу вакытында, елмаеп, ике кул белән кул биреп күрешү гадәте популяр. Хатын-кызларга исә кулларын кысарга ярамый, бу дини яктан да тыелган. Гадәттә, ир-атлар, гәүдәне гәүдәгә тидереп исәнләшә. Бу «Мин сиңа хөрмәттәмен» дигән мәгънәне белдерә. Өлкән яшьтәге әби-бабайлар үзләренең оныклары белән, иркәләүнең бер билгесе буларак, күзләреннән, кулларыннан яки маңгайларыннан үбеп исәнләшәләр [8, б. 56].

Сәламләү процессы вакытында үзбәк халкында вербаль булмаган чаралардан, уң кулны күкрәккә яки ике учны бер-берсе өстенә күкрәккә куеп, нейтраль сәламләү формасы бар. Шулай ук, үзбәк ир-атлары ике кулны кендек өлешенә куеп, башны бераз ия төшеп, өлкән һәм хөрмәтле кеше белән очрашканда, кунакларны сәламләп, туй капкасы янында басып торганда, кайгы уртаклашканда, сәламләү формасын кулланалар.

Үзбәк халкына гына хас булган исәнләшүнең тагын бер үзенчәлеге – киленнең каената-каенанасына һәм ир ягындагы туганнарына сәлам бирүе. Килен кеше каената һәм каенанасына хөрмәт күрсәтеп, бөгелеп, башын аска иеп исәнләшә. Алар шул вакытта: *«Бахитли болиң!» («Бәхетле бул!»), «Узак яшәң!» («Озак яшә!»), «Ул ту!» («Ул тап!»)* дигән теләкләрен дә белдерәләр [8, б. 59].

Үзбәкләрдә өлкәннәргә карата ихтирамлы мөнәсәбәт көчле. Балаларны кечкенәдән юл бирергә, әти-әниләренә һәм өлкән яшьтәге чит кешеләргә карата хөрмәтле булырга өйрәтәләр. Мондый мөнәсәбәт телдә дә чагылыш тапкан. Өлкәннәрне сәламли торган *«Бардаммисиз?»* дигән аерым гыйбарә кулланалар.

Татар телендә *исән, сау, сәламәт, имин* сүзләренә нигезләнгән исәнләшү гыйбарәләре еш күзәтелә. Татар әдәби телендә саулык, сәламәтлек, тынычлык, иминлек мәгънәләрен белдергән сүзләр нигезендә ясалган сорау җөмләләр рәвешендә төзелгән исәнләшү гыйбарәләре бай синонимик ояны тәшкил итә.

*Саумы* сүзе нигезендә сәламләшү: *Сау* сүзенә *-мы* кисәкчәсе өстәлә, *Сау* сүзенә фигыльләр өстәлеп ясалган исәнләшү гыйбарәләре актив кулланыла.

*Исән* сүзе нигезендәге сәламләшү гыйбарәләре: *Исәнме(сез)* гыйбарәсе дә – шактый борынгы форма.

*Исән* сүзенә *-ме* кисәкчәсе өстәлергә, хәбәрлек кушымчасының II зат күплек саны, *Исән* сүзенә *йөр-, яшә-, тор-* фигыльләре ялганып ясала ала.

*Исән-сау* парлы сүзе белән сәламләшү: сорау кисәкчәсе *исән-сау* парлы сүзенең һәр компонентына ялгана ала, шулай ук гына кисәкчәсе (Исән-сау гынамы?) һ.б.

*Таза-сау* парлы сүзе нигезендә ясалган сәламләшү гыйбарәләре: бу сүз *исән-сау* сүзе кебек үк төрләнешләргә кереп, сәламләшүдә файдаланыла. Парлы сүзнең компонентлары урыннарын алыштыра ала: *саулык-тазалык*.

*Имин* сүзе нигезендә сәламләшү күзәтелә: гарәп теленнән кергән ул «куркынычсыз», «ышанычлы», «тыныч» мәгънәләрен белдерә [13, б. 159]. Бу сүз үзебезнең *исән* кебек үк төрләнешләргә кереп, сәламләшүдә файдаланыла, ләкин аңа караганда пассиврак кулланыла. ***Имин** генә яшисезме?* ***Иминлекме** сездә?*

*Сәламәт* сүзе ярдәмендә исәнләшү күзәтелә: Аның *Сәламәтлекме? Сәламәтләрме?* вариантлары да бар. Гарәп теленнән кергән бу сүз *сәлам* сүзе белән тамырдаш, аның кебек үк *«иминлек», «куркынычсызлык», «исәнлек, саулык»* мәгънәләрен белдерә [13, б. 519].

*Сау-сәламәт* парлы сүзе: Бу сүз *исән-сау* сүзе кебек үк төрләнешләргә кереп, сәламләшүдә файдаланыла: *Сау**мы**-сәламәт**ме**?*

*Ни хәл* гыйбарәсе белән исәнләшү: *Хәл* сүзе гарәп телендәге *халь* сүзеннән үзгәреп кергән. Бу сүз гарәп телендә «торыш», «көч», «куәт» мәгънәләрен аңлата [13, б. 647]. *Ни* сорау алмашлыгы белән татар телендә халыкчан сәламләшү гыйбарәсенең үрнәге. Борынгы телдә бу сорау алмашлыгы *нә* булып әйтелгән: ***Нә халь,*** *нә хәбәрләр? Сәламәтлекму?* [14, б. 62].

*Ничек* сорау алмашлыгы һәм *тормыш, эш, кәеф* сүзләреннән ясалган хәл сорау гыйбарәләре бар: ***Ничек** соң **тормышың?*** ***Ничек кәефең?***.

*Кәеф* сүзе гарәп телендә «күңел торышы», «күңел хушлыгы», «саулык, сәламәтлек» мәгънәләрен белдерә [13, б. 222]. Бу сүз катнашкан исәнләшү гыйбарәләре шулай ук еш күзәтелә. Бу гыйбарәләрнең формалары *ничек* алмашлыгының *тормыш, эш* исемнәре белән килгәне кебек үк була: ***Кәефләрең ничек**?*

*Хәл* сүзе белән килгән *ничек* алмашлыгы: *Хәл* сүзенә тартым яки күплек сан кушымчалары ялганган булырга мөмкин: ***Хәлең ничек**?*

*Хәл-әхвәл(ләр) ничек?: Хәл* сүзе белән *әхвәл* сүзе, ягъни *хәл* сүзенең күплеге [13, б. 750] парлы сүз тәшкил итеп, *ничек, ничегрәк* сорау алмашлыклары белән сәламләшү гыйбарәсе буларак кулланыла: ***Хәл-әхвәлләр ничегрәк**?* Бу гыйбарә дә компонентларын алыштыра ала: *хәл-әхвәлләр ничек, ничек хәл-әхвәлләр?*

Сәламләшү гыйбарәләре сорау җөмлә нигезендә дә ясала ала. Бу очракта сәламләшү дә, хәл сорау да берьюлы башкарыла. Аның тагын төп компоненты хикәя фигыль булган түбәндәге төрләре бар: *ничек* + (йөри, тора, яши, кайта, ята) + -сың / -сең?; *ничек* + (йөри, тора, яши, кайта, ята) + -сың / -сең + соң?; *ничек* + (йөри, тора, яши, кайта, ята) + -сыз / -сез?; *ничек* + (йөри, тора, яши, кайта, ята) + -сыз / -сез + соң? һ.б.

Соңгы елларда *Как идут дела* гыйбарәсен хәтерләткән сәламләшү еш кулланыла. Монда *эш(ләр)* сүзе (исеме) түбәндәге формалар белән кушыла: …-ең + барамы; …-ең + барамы + соң; …-егез / -ыгыз + барамы; …-егез / -ыгыз + барамы + соң; …-ләр / -лар + ничек + бара; …-ләр / -лар + ничек + бара + соң; …-ләр / -лар + -ең / -ың + ничек + бара; …-ләр / -лар + -ең / -ың + ничек + бара + соң; …-ләр / -лар + -егез / -ыгыз + ничек + бара; …-ләр / -лар + -егез / -ыгыз + ничек + бара + соң?

Татар телендә исәнләшүнең пассиврак формалары да кулланылырга мөмкин. Мәсәлән, *хәлләр әйбәтме, хәлләр яхшымы* гыйбарәләре дә кулланыла.

Шулай ук *Кәеф әйбәтме, тормышлар яхшымы* тибындагы гыйбарәләр белән хәл сорашу да бар. *Арумы* сүзе белән исәнләшү күбрәк керәшен татарларында очрый.

*Ару* сүзе, Р. Әхмәтьянов әйткәнчә, «чистый», «здоровый» мәгънәләрен белдерә, ул мари, удмурт, чуваш телләрендә дә бар. Чыгышы ягыннан борынгы төрки *арыг* «чистартылган» дигән сүзгә барып тоташа [15, б. 20]. Шуңа күрә ул мөселман татарлары арасында да очрый, ләкин сирәк файдаланыла.

Шул рәвешчә, татар әдәби телендә исәнләшү гыйбарәләренең сорау җөмләләр нигезендә барлыкка килгәннәре күпчелекне тәшкил итә: *саумы, сау торасыңмы, исәнме, исән генә йөрисезме, исәнме-саумы, таза-сау*

*гына йөрисеңме, имин-аман торасызмы, сәламәтме, ни хәлләрдә яшисез, эшләр ничек бара, кәефләр ничек, ничек торасыз, хәлләр әйбәтме, арумы, ару ятасызмы* һ.б.

Сорау җөмләләргә нигезләнгән исәнләшү гыйбарәләренең ымлык функциясен үтәү очраклары күзәтелә: *исәнмесез, нихәл, саумы* һ.б. Ымлык функциясендәге бу гыйбарәләр узып баручыга игътибар күрсәтү билгесе булып кына йөриләр. Аларның күбесе сорау-кызыксыну модальлеген саклый һәм, әңгәмәдәш белән кызыксынуны, аңа зуррак игътибар күрсәтүне белдереп, якын итеп хөрмәт итү билгесе буларак әйтелә.

*«Ассалому алайкум!»* үзбәк телендә әдәби нейтраль исәнләшү гыйбарәсе булып тора. Бу гыйбарәгә җавап итеп *«Валайкум салом!»* гыйбарәсе кулланыла. Совет власте урнашканчы сәламләү гыйбарәсе үзбәкләрдә дә, татарларда да *«Ассалому алайкум ва раҳматуллоҳ», «Ассалому алайкум ва раҳматуллоҳу баракотух»* булган һәм сәлам кайтару формасы *«Валайкум ассалом!», «Валайкумусссалом ва раҳматуллоҳу ва баракотуҳ!»* булган. Бүгенге көндә әлеге гыйбарәләрне дин әһелләре генә актив куллана.

*«Ассалом»* исәнләшү гыйбарәсенең кече яшьтәге яисә туганнарга карата кулланыла торган түбәндәге вариантлары бар: *«Салом!»* (яшьләр арасында), *«Ассалому алайкум ва раҳматуллоҳ!» (өлкән яшьтәге кешеләргә карата)* һәм *«Саломатмисизлар!»* (берничә өлкән яшьтәге кешегә карата). Әдәплелек тел күрсәткече булып «сиз» кушымчасы тора, һәм ул икенче затка карата барлык этикет мөрәҗәгатьләрдә дә кулланыла.

Сәламләү гыйбарәсен сайлау аралашуда катнашучыларның таныш яки таныш булмавына бәйле. Әгәр алар таныш түгел икән, сәламләү, нигездә, адресатның яшенә бәйле: яшьтәшкә яки өлкән яшьтәге кешеләргә *«Ассалому алайкум!»* (ир-атка), *«Салометсизми*!» сәламләү сүзләре белән мөрәҗәгать итәләр, ә кече яшьтәге әңгәмәдәшләргә *«Салометсинми!»* йә «*Салом*!» дип әйтәләр.

Әгәр дә аралашу очрагында катнашучылар таныш икән, дуслар танышлар, туганнар бер-берсен *«Салом!» («Сәлам»!, «Исәнме!»), «Ҳелло!». «Привет!», «Салют!», «Қалай?», «Михдай!», «Гап йўқ», «Ништяк»* дип сәламлиләр.

Сәламләү формулаларын куллану шулай ук көнкүреш яки рәсми аралашуга бәйле. Рәсми сәламләү, кагыйдә буларак, аралашуның ритуаль элементы булып тора. *«Ассалом, ханымлар билан жаноблар!» («Исәнмесез, ханымнар һәм әфәнделәр!»)* кебек сәламләү формалары рәсми аралашу шартларында кулланыла.

Сәламләү гыйбарәсен сайлау әңгәмәдә катнашучы кешеләрнең җенесенә дә бәйле: *«Ассалому алайкум!»* дип, ир-атлар гына сәламли, һәм ир-атлар гына бу сәламне кабул итеп, *«Валайкум ассалом!»* дип җавап кайтара. *«Яхшимисиз?» («Яхшымысыз?»)* дип сәламләгән вакытта ир-атлар бер-берләренең кулларын кыса. Хатын-кызлар исә бер-берсен *«Омонмисиз?»* дип сәламли.

Ир белән хатын бер-берсеннән еракта булса, бер-берсен *«Тинч ўтирибсизлармиʔ»* дип сәламлиләр.

Үзбәк теле гыйбарәләрендә сәламләү әңгәмәдәшнең сәламәтлеге турында да сорау булып тора. *«Саломатмисизлармиʔ» («Исәнмесез, сез сәламәтме?»), «Саломатмисин?» («Исәнме, син сәламәтме?»), «Яхшимисиз?» («Исәнмесез, ничек хәлләр?»), «Сау-саломатсизми?« «(Исән-саулармы, ничек яшисез?»)* сүзләренең нигезендә *салом (сәламәт, имин), сау (сәламәт)* кебек исәнлекне, сәламәтлекне белдергән сүзләр ята. Шул ук вакытта үзбәк лингвомәдәниятендә адресатның сәламәтле-геннән тыш, аның туганнары, якын кешеләренең сәламәтлеге турында да сорашу, белешү кабул ителә, шул ук вакытта мондый сәламгә ягымлы җавабы *«Яхши», «Алҳамдуллуоҳ», «Худога шукур!», «Шукур», «Раҳмат», «Яхши» («Яхшы, рәхмәт»), «Гап йўқ»* була [16, б. 27].

Үзбәк телендә шулай ук «*Хайрли тонг!» («Хәерле иртә!»), «Хайрли кун!» («Хәерле көн!»), «Хайрли кеч!» («Хәерле кич»), «Хайрли тун!» («Хәерле төн»)* кебек сәламләү формулалары да бар. Аларны куллану адресатка карата ихтирамлы мөнәсәбәтне ассызыклый, мондый сәламләү сүзләрен хезмәттәшләр арасында ишетергә мөмкин, җитәкче хезмәткәрләре белән әнә шулай исәнләшергә мөмкин, өстәвенә, хезмәткәрләр дә шулай җавап кайтаралар.

**Нәтиҗә**

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар һәм үзбәк халкының аралашу мәдәниятендә сәлам бирүнең төп кагыйдәләре, нигездә, охшаш. Сәламләү гыйбарәләре арасында зур урынны

сорау җөмләләр алып тора. Очрашкан вакытта кешенең сәламәтлеге, тормыш-көнкүреше турында сораулар бирелә: «Исәнлек, саулыкмы?», «Исән-сау гына йөрисезме?» һ.б.

Кеше тормышында гадәти күренеш буларак, кешеләр төрле формада, төрле ысуллар ярдәмендә исәнләшә, бер-берсенә хәерле иртә, хәерле көн, хезмәттә уңыш, саулык-сәламәтлек, иминлек телиләр. Үзбәк телендә дә исәнләшү, сәлам бирү шулай ук хәл, исәнлек-саулык сорашу, кунакка чакыру гыйбарәләре белән үрелеп бара. Шул ук вакытта үзбәк лингвомәдәниятендә дә адресатның сәламәтлегеннән тыш, аның туганнары, якын кешеләренең сәламәтлеге турында да сорашу, белешү кабул ителә.

Татар һәм үзбәк халкының аралашу мәдәниятендә исәнләшү, сәлам бирү сөйләм актына бәйле күп төрле гыйбарәләр кулланыла. Исәнләшү, сәлам бирү сөйләм берәмлекләре еш кына хәл, исәнлек-саулык сорашу, өндәү, кунакка чакыру гыйбарәләре белән үрелеп бара.

Татар телендә **хәл сорау гыйбарәләре** бай синонимик ояны тәшкил итә: *саумы, исәнме, исәнлек-саулыкмы, таза-саумы, ни хәлләр, ни хәл, кәефләр ничек* һ.б.

Яхшы теләк белдереп исәнләшү – татар һәм үзбәк халкының яраткан исәнләшү үзенчәлеге. Гарәп телендәге «*әссәламегаләйкүм*» белән «*вәгаләйкемәссәлам*» кебек үзара сәламләшү гыйбарәләре безнең татар теленә озак еллар аша, татар халкы мөселманлыкка күчкән чордан килә. Көнкүрештә, әңгәмәдәшләр бер-берсе белән яхшы таныш вакытта сүзне «*Сәлам*» дип башларга мөмкин.

*«Привет», «салют»* кебек рус-Европа алынмалары белән исәнләшү сирәк күзәтелә. Яхшы теләк белдереп сәламләү гыйбарәләре вакыт аралыгына, тәүлек вакытына да бәйле булырга мөмкин.

Озак очрашмый торган кешеләр бер-берсе белән шатланып, «*Сине күрергә шатмын!», «Менә нинди очрашу», «Нинди көтелмәгән хәл!», «Менә шулай очрашу!», «Мин кемне күрәм!», «Нинди язмышлар ташлады?», «Күрешмәгәнгә биш былтыр!»* дип тә исәнләшергә мөмкин. Мунчадан чыккан кешеләрне: *«Җиңел пар белән!»* дип сәламләү гадәте бар.

Үзбәк телендә дә исәнләшү, сәлам бирү сүзләре киң таралган: *«Саломатмисизлармиʔ» («Исәнмесез, сез сәламәтме?»), «Саломатмисин?» («Исәнме, син сәламәтме?»), «Яхшимисиз?» («Исәнмесез, ничек хәлләр?»), «Сау-саломатсизми?» («Исән-саулармы, ничек яшисез?»)* һ.б.

Вакыт аралыгына, тәүлек вакытына бәйле яхшы теләк белдереп исәнләшү гыйбарәләре казах теленә дә хас: «*Хайрли тонг!» («Хәерле иртә!»), «Хайрли кун!» («Хәерле көн!»), «Хайрли кеч!» («Хәерле кич»), «Хайрли тун!» («Хәерле төн!»)*.

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, исәнләшү төрле вербаль булмаган чаралар, хәрәкәтләр белән үрелеп бара. Исәнләшкәндә, татарлар баш ию, кул сузу, кул кысу кебек хәрәкәтләр куллана.

Исәнләшү гыйбарәләре семантик яктан хәл сорау һәм яхшы теләк белдерү мәгънәләрен белдерә. Бу мәгънәләр исәнләшү, сәламләшү гыйбарәләренең нигезендә ята. Моннан тыш, исәнләшү сөйләм акты мөрәҗәгать итү, танышу, исәнлек, саулык, хәл сорашу, чакыру, кунакчыллык күрсәтү кебек башка сөйләм актлары белән бәйләнә.

Татар һәм үзбәк лингвомәдәниятендә исәнләшү актының коммуникатив-прагматив калыпларын да билгеләргә мөмкин: исәнләшү + мөрәҗәгать итү; исәнләшү + танышу; исәнләшү + исәнлек-саулык, хәл-әхвәл сорашу; исәнләшү + чакыру, кунакчыллык күрсәтү; сәламләү + тәкъдим итү; исәнләшү + котлау, теләк; исәнләшү + рөхсәт сорау; исәнләшү + сорау бирү; исәнләшү + рәхмәт белдерү; исәнләшү + үтенеч; исәнләшү + дога кылу.

Кардәш халыкларның этикет гыйбарәләрен чагыштырып өйрәнү – бүгенге коммуникатив лингвистикада әйдәп баручы юнәлешләрнең берсе. Тикшеренүләр бу милләтләрнең аралашуындагы уртак һәм аермалы якларны билгеләргә, сөйләм теле формалашудагы үзенчәлекләрне табарга ярдәм итә. Бу төр эзләнүләр әле башланып кына килә, киләчәктә алар күп телләр материалында башкарылыр дип уйлыйбыз.

Тикшеренү эше ФПСП-2/24 темасы кысаларында башкарылды.

**Әдәбият**

1. Шәйхиева Г.М. Сүзьясалышы һәм сөйләм әдәбе // Проблемы словообразования в тюркских языках. Казан: Фикер, 2002. Б. 319–323.

2. Сафиуллина Ф.С., Фатхуллова К.С. Татарский речевой этикет // Татарский язык: Интенсивный курс. Казань: Хәтер, 1999. 37 с.

3. Лингвистический энциклопедический словарь / Гл. ред. В.Н.Ярцова. М.: Советская энциклопедия, 1990. С. 413.

4. Формановская Н.И. Речевой этикет и культура общения. М.: Русский язык, 1997. 128 с.

5. Абдуллин А.А. Этические выражения в современном татарском литературном языке: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2006. 200 с.

6. Муминова А. А. Узбекский речевой этикет: сен (ты), сиз (вы, вы) // Вестник Российского университета дружбы народов. Серия: Теория языка. Семиотика. Семантика. 2015. №3. С. 34–40.

7. Миртожиев М., Маҳмудов Н. Тил ва маданият. Тошкент: Ўзбекистон, 1992. 128 с.

8. Ҳожиева Ҳ.Я. Ўзбек тилида ҳурмат майдони ва унинг лисоний-нутқий хусусияти: Филол. фан. номз. ... дисс. Самарқанд, 2001. 168 с.

9. «Ниса (Хатыннар)» сүрәсе, 86 нчы аять – http://dumrt.ru/articles/mm-islam/mm-islam_5141.html

10. https://tt.wikipedia.org/wiki

11. https://abishevaalena.ru/?page_id=488

12. Насыйри К. Китаб-эт-тәрбия. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 144 б.

13. Мәхмүтов М.И., Хәмзин К.З., Сәйфуллин Г.Ш. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге (татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре) 2 т. Казан: Иман, 1993. 786 б.

14. Бигиев З. Зур гөнаһлар. Казан: Тат. кит. нәшр., 1991. 228 б.

15. Әхмәтьянов Р. Р. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 272 б.

16. Тоирова Г. И. Нутқий мулоқотнинг прагматик таҳлилида система тушунчаси // Филология масалалари. – Тошкент: ЎзДЖТИ, 2009. № 1. Б. 26–31.

# КОММУНИКАТИВНО-ПРАГМАТИЧЕСКОЕ ИСПОЛЬЗОВАНИЕ ПРИВЕТСТВЕННЫХ ВЫРАЖЕНИЙ В ТАТАРСКОЙ И УЗБЕКСКОЙ ЛИНГВОКУЛЬТУРАХ

**Фируза Рамзилевна Сибгаева**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
FiruzaRS@mail.ru.

**Гули Ибрагимовна Тоирова**,
Бухарский государственный университет,
Узбекистан, 200114, г. Бухара, ул. М. Икбола, д. 11,
tugulijon@mail.ru.

Данная работа выполнена в русле теории коммуникативной лингвистики с учетом положений теории межкультурной коммуникации. Объектом данного исследования выступают речевые этикетные выражения приветствия на двух языках: татарском и узбекском. Предметом исследования являются прагмалингвистические особенности нормативной вежливости в указанных лингвокультурах. В статье представлены итоги сравнительно-сопоставительного анализа приветственных выражений в татарском и узбекском языках. В ходе исследования выявлены языковые, речевые, коммуникативные различия и сходства, особенности национального сознания, раскрыты особенности структуры этих языков. Статья имеет практическую направленность. В ходе исследования применялись методы и приемы наблюдения, сравнения, компонентного анализа.

**Ключевые слова:** татарский язык, узбекский язык, культура диалога, культура общения, лингвокультурология

Исследование выполнено в рамках темы ФПСП-2/24.